ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«12» май 2025 ел** **№ 9**

**Яңасала авыл җирлеге территориясендә**
**пиротехника эшләнмәләреннән**
**файдалану турында**

РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 28 августындагы "Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның Бердәм системасы турында" 901 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы "Россия Федерациясе Һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында" 138 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган РФдә янгынга каршы режим кагыйдәләре нигезендә, Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Пиротехник әйберләрдән файдалану өчен рөхсәт ителгән урын итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:
- Яңасала авылында, елга аша чыккан күпердә.
- Каенсар авылына керү юлындагы плотинада.

Биеклеге 50 метрдан артыграк булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә һава пространствосыннан файдалану Россия Федерациясе Һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы оператив органы (алга таба - Вәкаләтле орган)рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 6 декабрендәге «Яңа ел бәйрәм чараларын

уздыруга әзерлек һәм бәйрәмнәр вакытында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында» 14 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңасала авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт; Каенсар авылы, Урта урам, 25 йорт.

4. Әлеге карарны куллануны контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңасала авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

А.И.Сафин